**Укыту һәм тәрбия эшчәнлегендә туган тел һәм халкыбыз традицияләре.**

Үзенә генә хас милли традицияләре, кәсепләре һәм бөтен дөньяга танылган бөек шәхесләре булган татар авыллары бик күп. Безнең Аксу авылы да Борһа Шаһидие, тирә-якта данлыклы Шәрәфләр нәселе һәм алардан калган кишер үстерү кәсебе белән аерылып тора. Аксу авылындагы мәктәпнең дә тарихы Шәрәфләр исеменә барып тоташа. Чөнки беренче зур мәктәп Шәрәфләр булышлыгы белән нәкъ менә Аксу авылында салына. Тирә-яктагы авыл балалары, хәтта күрше район авылларыннан да шушы мәктәпкә килеп укыйлар. Ераклардан килгән балаларга торып укыр өчен интернаты да була аның. Бүгенге көндә Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “ТР Буа муниципаль районы Аксу урта мәктәбе”ндә Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасы халыкларының телләре” турындагы Закон һәм “ Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү турындагы Программасы”н тормышка ашыру юнәлешендә күпкырлы укыту һәм тәрбия эшләре алып барыла.

Аксу урта мәктәбе Буа районында татар мәктәбе. Мәктәптә укыту һәм тәрбия процессы нигездә татар телендә алып барыла; югары сыйныфлар фәннәрне рус телендә укыйлар. Бүгенге көндә мәктәптә 61 бала белем ала. Алар барысы да татар милләтеннән. Бездә башка мәктәптән килеп укучы яки башка төбәктән кайткан укучылар юк. Шуңа күрә татар телен өйрәнүгә бөтен шартлар да бар. 100% укучылар татар телен туган тел буларак өйрәнәләр. Башлангыч сыйныфта (1-4 с.) атнага барлыгы 21 сәгать татар теле һәм әдәби уку укытыла; урта сыйныфларда (5-9 с.)-23 сәгать; югары сыйныфларда (10,11 с.)-6 сәгать татар теле һәм әдәбияты укытыла.

Укучыларның фәннәр буенча ЕГЭ күрсәткечләре начар түгел.

Дәрестән тыш эшчәнлек укыту-тәрбия эшенең аерылгысыз өлеше, балаларның буш вакытларын максатчан оештыруның бер юнәлеше булып тора. Мәктәбебез укучылары сыйныф җитәкчеләре һәм фән укытучылары җитәкчелегендә мәктәп, муниципаль, республика, төбәкара бәйгеләрдә,

фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнашалар. Белгәнебезчә, һәр елны ТР фән һәм мәгариф министрлыгы, ТР язучылар берлеге тарафыннан түбәндәге төбәкара һәм республика күләмендәге фәнни-гамәли конференцияләр үтә. Алар: **“Шәҗәрәләр – нәсел агачы”,“ Кояшлы ил”, “Киләчәге бар милләт без, Шәхесләргә бай милләт без”,”Моя малая Родина”.**Бу бәйгеләрдә безнең укучылар бик теләп катнашалар һәм җиңүчеләр, призерлар булалар.

Туган тел – ата-бабаларыбыздан калган иң кыйммәтле мирас. Безнең бурыч- аны түкми-чәчми буыннан буынга тапшыру. Һәр елны туган тел буенча белемнәрне тикшерү, грамоталылыкны бәяләү, туган телне пропагандалау, төрле млләтләрнең традицияләрен, гореф-гадәтләрен барлауга багышланган төрле бәйгеләр, акцияләр оештырыла. Шундыйлардан: **“Живая классика”**;башлангыч сыйныф укучылары өчен **“Хочу все знать**” төбәкара бәйгеләре; Бөтендөнья **“Татарча диктант”,** (Аксу урта мәктәбе базасында) **“Этнографик диктант” акцияләре (онлайн форматта).** (2020 нче елда “Татарча диктант”та 65 кеше, “Этнографик диктант”та 17 кеше катнашты).

Дәрестән тыш эшләрнең мондый төрләре укучыларда туган телгә булган игътибарны, аның белән кызыксынуны тагын да арттыра һәм югарырак үрләргә рухландыра.Шуңа күрә укучыларыбыз бик теләп киңрәк масштаптагы бәйгеләргә дә тартылалар. Шундыйларның берсе, мәсәлән, һәр елны үткәрелә торган фәнни-гамәли конференция “Лингвокультурология: проблемы и перспективы...” Ул Казан шәһәрендә үткәрелә. 10 нчы халыкара конференциядә 11 нче сыйныф укучысы Мухаметзанова Сиринә катнашты һәм “Иң яхшы чыгыш” дигән дипломга ия булды.. Җитәкчесе: татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гобәйдуллина И.И.

Укучыларны матур әдәби әсәрләрне укуга тарту, талантлы укучыларны барлау, укучыларның эзләнү эшчәнлеген үстерү мксатыннан һәр ел саен Л.Н. Толстой исемендәге фәнни-гамәли конференция үткәрелә.

Безнең укучыларыбыз рус теле укытучысы Хайбуллин И.У. җитәкчелегендә ул конференциядә бик теләп катнашалар.

Бу конференциянең төрле секцияләре эшчәнлегендә катнашып, безнең укучылар призлы урыннарга лаек булдылар.

Укучыларда сүз сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, туган телнең матурлыгын тоярга өйрәтү, сәнгатьле сөйләм эшчәнлеген үстерү максатыннан һәр елны **“Җәлил укулары**” дигән халыкара әдәби бәйге үтә., Анда укучылар М.Җәлил шигырьләрен, М.Җәлилгә багышланган башка шагыйрьләрнең шигырьләрен һәм үзләре иҗат иткән шигырьләрне сөйләп призлы урыннарга лаек булалар. Быел ул онлайн форматта узды, шуңа күрә катнашучыукучылар да күп булды. Быелгы муниципаль этапта коллектив рәвештә чыгыш ясап, 8 нче сыйныф укучылары җиңүче, ике укучы призер, ике укучы лауреат булдылар.

21 нче февраль -Халыкара Туган телләр көне уңае белән, укучыларда милли үзаң тәрбияләү, туган телләргә ихтирам арттыру, гореф-гадәтләребезне җиткерү, башка халыкларның телләренә һәм гореф-гадәтләренә ихтирам тәрбияләү максатыннан үткәрелгән “Бердәм гаиләдә” (“В семье единой” ) фестивалендә дә бик теләп катнашабыз. Иң элек бу бәйрәм авыл китапханәсе, авыл мәдәният йорты белән берлектә мәктәптә үткәрелә. Мәктәптә җиңүчеләр район күләмендәге бәйгегә тәкъдим ителә. Быелгы уку елында район күләмендәге элеге фестивальдә 5 укучы катнашты һәм призлы урыннарга лаек булдылар.

Һәр елны фән олимпиадаларында катнашабыз. Соңгы 3 елда фән олимпиадаларының муниципаль этабында уңышларыбыз түбәндәгечә:

2018 нче елда җәмгыять белеме, рус теле, литература, татар теле, әдәбият фәннәре буенча 8 призлы урын; 2019 нчы елда биология, татар теле, әдәбият буенча 8 призлы урыныбыз булды.

2019-20 нче уку елында татар теле һәм әдәбияты буенча 2 укучы республикакүләм олимпиадада призер булдыларШулай ук Казанда КФУ оештырган халыкара олимпиадада да катнашабыз. 2020-2021 нче уку

елындагы фән олимпиадаларында 9 призлы урыныбыз булды. Укучылар биология, математика, татар теле фәннәреннән уңышларга ирештеләр. . Финансовая грамотность һәм предпренимательство буенча ике укучыбыз Казанга барып олимпиадада катнаштылар һәм призерлар булдылар. Грамоталар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнделәр. Җитәкчеләре тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Камалиева Гүзәл Завитовна

Грамоталы укучыларны билгеләү, рус телен өйрәнүгә кызыксыну уяту, ата-аналарның да игътибарын җәлеп итү максатыннан мәктәптә **«Грамотность на кончике пера** (на русском языке)», дигән бәйге үткәрелә. Анда 2-11 нче сыйныфка кадәр укучылар катнаша. Җиңүчеләр район күләмендәге бәйгегә тәкъдим ителә.

Укытучылар да иҗади эшлиләр. Үзләре дә профессиональ бәйгеләрдә катнашалар.

- татар теле һәм әдәбияты укытучысы “Иң яхшы татар теле укытучысы”дигән профессиональ бәйгедә катнашып, муниципаль этапта җиңүче булды.

Мәктәбебез һәм районыбыз данын зона этабында яклады.

- математика укытучысы Галяутдинова Л.М. “Сыйныф җитәкчесе - 2019”. бәйгесендә муниципаль этапта призер булды.
- биология укытучысы Шафигуллина Д.И. “Ел укытучысы – 2019”. бәйгесендә лауреат булды.

Югарыда саналган бәйгеләрдән тыш мәктәбебездә халкыбызның гореф-гадәтләрен, бәйрәмнәрен яңарту, укучыларга җиткерү максатыннан күп төрле чаралар үткәрелә. “Нәүрүз”, “Сөмбелә”, “Солдат озату” бәйрәмнәре мәктәп укучылары, ата-аналар, укытучылар, авыл яшьләре катнашында авыл мәдәният йортында бик зурлап үткәрелә. Әдәби-музыкаль кичәләр, халык авыз иҗатына багышланган интеллектуаль уеннар, ветераннар, әфганчылар һәм Чечня сугышында катнашкан солдатлар белән очрашулар авыл җирлеге башлыгы, ата-аналар катнашында үтә. Республикакүләм бәйгеләрдә, интеллектуаль уеннарда катнашабыз: “Тамчы-шоу”, Шаян ТВ, “Салават күпере” журналы үткәргән бәйгеләр; төрле язучы-шагыйрьләрнең иҗатларына багышланган акцияләр; рәсем, сочинение конкурслары; финанс

грамоталылыгы олимпиадалары һ.б. Менә инде 4 нче тапкыр Бөтендөнья “Әдәби марафон”ында катнашып киләбез. Ул 21 көн дәвам итә. Бу марафонга укучылар гына түгел, ә әти-әниләр дә, укытучылар да, авыл халкы да тартыла. Соңгы марафонда безнең мәктәптән 31 кеше катнашты, 10 әни безгә кушылды.

Милли тәрбия  интеллектуаль һәм рухи яктан үскән шәхес тәрбияләүгә киң мөмкинлекләр ача.Үз кыйбласы, таяну ноктасы булган коллектив кына зур уңышларга ирешә ала. Безнең өчен ул туган тел, халкыбызның традицияләре. Шуңа да безнең коллектив бөек татар мәгърифәтчесе, тел галиме К.Насыйриның түбәндәге  фикерләрен эшкә нигез итеп ала.
«Берәү башка телне өйрәнмәкче булса, башта үз теленең грамматикасын яхшы белсен!”
  Без үзебезнең тарихыбыз, туган телебез, мәктәбебез уңышлары белән горурланабыз.
  Ләкин кайбер хәл ителәсе мәсьәләләр дә юк түгел. Сыйфатлы белем бирү күрсәткечләрен үстерү, олимпиадаларда уңышларны арттыру. Моның өчен мәктәпнең материаль-техник базасын ныгытырга, яңартырга кирәк. Кабинетларга яңа җиһазлар, интерактав такталар, физика, химия фәннәре буенча лабораторияләргә приборлар, тәҗрибәләр үткәрү өчен материаллар кирәк.